**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**

# КАРАРЫ

2015 елның «12» февраленнән — № 41-242

**«Муниципаль хезмәтне үстерү муниципаль программаларын гамәлгә ашыру барышында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында җирле үзидарә органнары, муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән экспериментлар үткәрү тәртибе, шартлары һәм сроклары турында Нигезләмәне раслау хакында»**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елнын 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 41 статьясы нигезендә, муниципаль хезмәтне үстерү муниципаль программаларын гамәлгә ашыру барышында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнарында җирле үзидарә органнары, муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Муниципаль хезмәтне үстерү муниципаль программаларын гамәлгә ашыру барышында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында җирле үзидарә органнары, муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән экспериментлар үткәрү тәртибе, шартлары һәм сроклары турында өстәмә нигезләмәне расларга. (1 нче кушымта)
2. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** — **В. М. Козлов**

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә мунципаль районы
Советының
2015 елның «12» февраленнән
41-242 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында җирле үзидарә органнары, муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән экспериментлар үткәрү тәртибе, шартлары һәм сроклары турында

НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге нигезләмә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 41 статьясы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органы), муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән экспериментлар үткәрү тәртибен, шартларын һәм срокларын билгели (алга таба -- экспериментлар).
2. Экспериментлар түбәндәгечә үткәрелергә мөмкин:
бер яки берничә җирле үзидарә органында;
җирле үзидарә органының структур бүлекчәсендә билгеләнгән тәртиптә юридик зат статусы бирелгән (алга таба-структур бүлекчә).
3. Экспериментлар түбәндәге максатларда үткәрелергә мөмкин:
җирле үзидарә органының яисә сайлау комиссиясенең эшчәнлеген планлаштыруның һәм финанслауның , җирле үзидарә органнарында яисә сайлау комиссиясендә һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыруның яңа ысулларын үз эченә алган идарәнең заманча технологияләрен апробацияләү һәм кертү;
җирле үзидарә органнары яисә сайлау комиссиясе эшчәнлеген, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеген бәяләү күрсәткечләре һәм критерийлары системасын апробацияләү һәм гамәлгә кертү;
муниципаль хезмәткәрләр хезмәте өчен түләүне камилләштерү һәм эшчәнлеген регламентацияләү;
муниципаль хезмәтне финанс-икътисадый һәм матди-техник тәэмин итүне камилләштерү;
җирле үзидарә органының яисә сайлау комиссиясенең структурасын һәм штат санын оптимальләштерү;
муниципаль хезмәткәрләрне әзерләү һәм һөнәри үстерү системасын камилләштерү;
җирле үзидарә органы (структур бүлекчә) яисә сайлау комиссиясе эшчәнлеген камилләштерүгә һәм муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри хезмәт эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә бәйле башка максатларга ирешү.

4. Эксперимент үткәрү турындагы карар җирле үзидарә органының муниципаль хокукый акты (муниципаль хезмәтне үстерүнең муниципаль программасы эксперимент үткәрүгә каралган сайлау комиссиясе рәисенең хокукый акты) рәвешендә кабул ителә.
5. Экспериментны үткәрү турында җирле үзидарә органының муниципаль хокукый акты (сайлау комиссиясе рәисенең хокукый акты) структур бүлекчә атамасында (эксперимент структур бүлекчәдә уздырылган очракта), экспериментның максатларын, бурычларын һәм эчтәлеген, аны үткәрү вакытын, финанслау күләмнәрен тасвирлау.
6. Эксперимент җирле үзидарә органында (структур бүлекчәдә) яисә сайлау комиссиясендә, җирле үзидарә органы җитәкчесе раслаган план-график нигезендә, муниципаль хокукый акт чыгарылган көннән алып 10 көн эчендә сайлау комиссиясе рәисе тарафыннан үткәрелә.
План-графикта түбәндәгеләр булырга тиеш:
1) эксперимент үткәрүнең сроклары, методы һәм рәвеше;
2) эксперимент уздыру этаплары һәм һәр этаплардан көтелгән нәтиҗәләр;
3) тәҗрибә нәтиҗәләренең дөреслеген тикшереп тору һәм тәэмин итү чаралары;
4) тулаем алганда эксперимент нәтиҗәләре буенча хисаплылык формалары һәм аның һәр этабын аерым-аерым;
5) экспериментны һәр этапта кадрлар, икътисадый, матди-техник һәм фәнни яктан тәэмин итү күрсәткечләре;
6) эксперимент үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат, шулай ук эксперимент этапларының һәркайсын үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затлар;
7) эксперимент үткәрүнең көтелгән нәтиҗәләре.
7. Эксперимент (эксперимент этабы) үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат план-график нигезендә эксперимент үткәрүнең кирәкле оештыру, методик һәм матди шартларын (эксперимент этабын) тәэмин итә.
8. Эксперимент үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерүнең тиешле программасын гамәлгә ашыруга каралган муниципаль берәмлекнең җирле бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.
9. Эксперимент үткәрү вакытында муниципаль хезмәткәрнең - экспериментта катнашучының хезмәт килешүе шартларын үзгәртү Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Экспериментны үткәрү эксперимент башланган вакытка әлеге хезмәткәрнең акчалата хезмәт хакы белән чагыштырганда, экспериментта катнашучы муниципаль хезмәткәрнең акчалата хезмәт хакы кимүгә, шулай ук эксперимент башланган вакытка муниципаль хезмәткәр биләгән вазыйфаның түбәнәюенә китерергә тиеш түгел.
10. Экспериментны үткәрү срогы кимендә 30 календарь көн һәм 12 айдан да артмаска тиеш.
11. Экспериментның барышы һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат, Россия Федерациясе законнары нигезендә, экспериментта һәм массакүләм мәгълүмат чараларында катнашучы органның рәсми сайтында урнаштырыла.

12. Эксперимент үткәрү турында йомгаклау отчеты җирле үзидарә органы (структур бүлек) җитәкчесе, сайлау комиссиясе рәисе тарафыннан, эксперимент тәмамланган көннән алып 30 календарь көн эчендә раслана.

13. Эксперимент үткәрү турында йомгаклау отчеты түбәндәгеләрне үз эченә ала:

эксперимент үткәрү барышында башкарылган чаралар тасвирламасы;

эксперимент үткәрү барышында ирешелгән максатлар һәм хәл ителгән бурычлар турында белешмәләр;

экспериментның башка җирле үзидарә органнарында уңай нәтиҗәләрен куллануның мөмкинлекләре, тәртибе һәм рәвешләре турында белешмәләр;

эксперимент нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәтне норматив-хокукый җайга салуны камилләштерү турындагы тәкъдимнәрне;

эксперимент нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәтнең нәтиҗәлелеген арттыру турында тәкъдимнәрне.

14. Эксперимент барышында ирешелгән максатларны һәм бурычларны анализлау нигезендә эксперимент тәмамланган көннән алып туксан календарь көн дәвамында җирле үзидарә органы җитәкчесе (сайлау комиссиясе рәисе) эксперимент нәтиҗәләрен җирле үзидарә органында (структур бүлекчәдә), сайлау комиссиясендә файдалануның максатчанлыгы турында карар кабул итә.